КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 13 июль г.Казань № 572

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә хезмәт күрсәтә торган транспорт чараларының норматив саны, үткән юлы һәм аларны агымдагы карап тоту чыгымнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2018 ел, 1 декабрь, 1073 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә хезмәт күрсәтә торган транспорт чараларының норматив саны, үткән юлы һәм аларны агымдагы карап тоту чыгымнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2018 ел, 1 декабрь, 1073 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 7 март, 165 нче; 2019 ел, 17 май, 402 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта:

егерме дүртенче һәм егерме бишенче абзацларга «(ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен транспорт чараларыннан башка» сүзләрен өстәргә)»;

егерме алтынчы һәм егерме җиденче абзацларны төшереп калдырырга;

егерме бишенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренең оператив идарәсендә булган ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен транспорт чараларын агымдагы карап тотуга норматив еллык чыгымнарны;

ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен транспорт чараларына аутсорсинг хезмәтләре күрсәтүгә түләү өчен норматив чыгымнарны;

Хезмәт урынында куллану максатларында шәхси транспорттан файдаланган өчен компенсация бирү турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарына һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләргә хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын (ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен транспорт чараларыннан башка) агымдагы карап тотуга норматив еллык чыгымнарны исәпләү тәртибен;

Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен транспорт чараларын агымдагы карап тотуга норматив еллык чыгымнарны исәпләү тәртибен.»;

2 нче пунктта:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«транспорт чараларын (ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүнең транспорт чараларыннан башка) агымдагы карап тотуга факттагы еллык чыгымнар, финанслау чыганаклары нинди булуга карамастан, транспорт чараларын агымдагы карап тотуга (транспорт чараларын федераль бюджет акчасы исәбеннән карап тотудан, машина йөртүчеләрнең хезмәте өчен түләү шартларын җайга сала торган норматив хокукый актлар белән күздә тотылган машина йөртүчеләргә эш хакы түләүгә нормативтан тыш чыгымнардан, берничә сменалы машина йөртүчеләр эшен күздә тота торган берничә сменада транспорт чараларын файдаланудан, транспорт һәлакәте һәм транспорт чарасын ремонтлау һәм яңадан торгызу зарурлыгына китергән башка вакыйгалар аркасында транспорт чарасын ремонтлауга һәм яңадан торгызуга бәйле чыгымнарны гамәлгә ашырудан башка) норматив еллык чыгымнардан артмаска тиеш;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүнең транспорт чараларын барлык финанслау чыганаклары исәбеннән агымдагы карап тотуга факттагы еллык чыгымнар ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүнең транспорт чараларын агымдагы карап тотуга (транспорт һәлакәте һәм транспорт чарасын ремонтлау һәм яңадан торгызу зарурлыгына китергән башка вакыйгалар аркасында транспорт чарасын ремонтлауга һәм яңадан торгызуга бәйле чыгымнарны гамәлгә ашырудан башка) норматив еллык чыгымнардан артмаска тиеш.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларында (иң чик санында) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлында:

1 нче таблицада:

27 нче һәм 28 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «27. | Казан шәһәренең «Ашыгыч медицина | | 7 | җиңел автомобиль | 17 010 | 70 |
| | | | 2 | микроавтобус/фургон | 60 750 | 250 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | ярдәме күрсәтү станциясе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | | 106 | ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен микроавтобус/фургон | | |
| | | | 78 | шул исәптән тәүлек буе кизүдә | 94 170 | 258 |
| | | | 4 | башкалар (мотоцикл) | | |
| | | | 2 | шул исәптән кизүдә | 9 000 | 50 |
| 28. | Яр Чаллы шәһәренең «Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү станциясе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | | 3 | җиңел автомобиль | 32 805 | 135 |
| | | | 2 | микроавтобус/фургон | 60 750 | 250 |
| | | | 43 | ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен микроавтобус/фургон | | |
| | | | 28 | шул исәптән тәүлек буе кизүдә | 87 600 | 240»; |

30 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «30. | «Әлмәт ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү станциясе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | | 2 | җиңел автомобиль | 32 805 | 135 |
| | | | 2 | микроавтобус/фургон | 32 805 | 135 |
| | | | 18 | ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен микроавтобус/фургон | | |
| | | | 11 | шул исәптән тәүлек буе кизүдә | 65 700 | 180»; |

95 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «95. | Үзәк район хастаханәсе (41 учреждениегә) | | 173 | җиңел автомобиль | 48 600 | 200 |
| | | | 212 | микроавтобус/фургон | 32 805 | 135 |
| | | | 189* | ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен микроавтобус/фургон **** | | |
| | | | 133,5* | шул исәптән тәүлек буе кизүдә | 65 700 | 180 |
| | | | 4** | йөк автомобиле | 17 010 | 70 |
| | | | 2*** | автобус | 12 150 | 50»; |

түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | «шул исәптән ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен транспорт чаралары | | 360 | | | |
| | шулардан тәүлек буе кизүдә ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен транспорт чаралары | | 250,5»; | | | |

искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«*Үзәк район хастаханәләренең 1 нче таблицада күрсәтелмәгән ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативлары 2 нче таблицада бирелә.

**«Буа үзәк район хастаханәсе», «Чистай үзәк район хастаханәсе», «Аксубай үзәк район хастаханәсе», «Кукмара үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләре өчен бер йөк автомобиле буенча.

***«Зеленодольск үзәк район хастаханәсе», «Лениногорск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләре өчен бер автобус буенча.

****Юридик затларны аларның төп персоналы санын 80 процентка кадәр саклап калып берләштергәндә, берләштерелә торган барлык оешмаларның транспорт чараларының норматив саны яңа юридик зат исемендә саклана.»;

2 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 нче таблица

| Т/с | Дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе исеме | Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен микроавтобусларның/ фургоннарның норматив саны, берәмлек | Шул исәптән тәүлек буе кизүдә, берәмлек |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 4 | 4 |
| 2. | «Азнакай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 6 | 5,5 |
| 3. | «Аксубай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 3 | 2 |
| 4. | «Актаныш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 3 | 3 |
| 5. | «Азнакай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 3 | 2 |
| 6. | «Әлки үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 2 | 1,5 |
| 7. | «Апас үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 2 | 1 |
| 8. | «Арча үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 5 | 2 |
| 9. | «Этнә үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау | 1 | 1 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | учреждениесе | | |
| 10. | «Баулы үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 3 | 3 |
| 11. | «Балтач үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 3 | 2 |
| 12. | «Бөгелмә үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 10 | 7,5 |
| 13. | «Буа үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 4 | 2 |
| 14. | «Югары Ослан үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 2 | 1,5 |
| 15. | «Биектау үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 5 | 2 |
| 16. | «Чүпрәле үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 2 | 1,5 |
| 17. | «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 9 | 5 |
| 18. | «Зәй үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 5 | 4,5 |
| 19. | «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 17 | 13,5 |
| 20. | «Кайбыч үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 1 | 1 |
| 21. | «Кама Тамагы үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 1 | 1 |
| 22. | «Кукмара үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 5 | 2,5 |
| 23. | «Лаеш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 4 | 3 |
| 24. | «Азнакай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 8 | 6,5 |
| 25. | «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 4 | 3 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 26. | «Менделеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 3 | 2 |
| 27. | «Минзәлә үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 3 | 2 |
| 28. | «Мөслим үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 2 | 1,5 |
| 29. | «Түбән Кама үзәк район күпюнәлешле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 28 | 15 |
| 30. | «Яңа Чишмә үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 1 | 1 |
| 31. | «Нурлат үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 6 | 4 |
| 32. | «Питрәч үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 4 | 2,5 |
| 33. | «Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 3 | 3 |
| 34. | «Саба үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 3 | 2 |
| 35. | «Сарман үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 3 | 2 |
| 36. | «Спас үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 2 | 2 |
| 37. | «Тәтеш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 2 | 2 |
| 38. | «Тукай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 4 | 3 |
| 39. | «Теләче үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 1 | 1 |
| 40. | «Чирмешән үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 2 | 1 |
| 41. | «Чистай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 8 | 6 |
| 42. | «Ютазы үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 2 | 2 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | Барлыгы | 189 | 133,5»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларының (иң чик санының) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлының 3 нче пунктында «32 805» һәм «135» саннарын шул ук эзлеклелектә «40 095» һәм «165» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларының (иң чик санының) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлының 2 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «2. | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Энергия саклау технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесе | | 6 | җиңел автомобиль | 32 805 | 135»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларында (иң чик санында) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлында:

4 графа исемендә «Татарстан Республикасы бюджеты акчасына карап тотыла торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «9. | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге (44 учреждениегә) | | 44 | җиңел автомобиль | 17 010 | 70 |
| | | | 44 | җиңел автомобиль | 26 730 | 110 |
| | | | 44 | җиңел автомобиль/ микроавтобус/фургон | 26 730 | 110 |
| | | | 43 | җиңел автомобиль | 32 805 | 135»; |

«Барлыгы» юлында «414» саннарын «457» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларын (иң чик санын) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлын (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарына һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләргә хезмәт күрсәтә торган транспорт чараларын агымдагы карап тотуга норматив еллык чыгымнарда:

исемендә татарча текста «транспорт чараларын» сүзләреннән соң «(ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен транспорт чараларыннан башка)» сүзләрен өстәргә;

искәрмәнең 9 нчы пункты үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарына һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләргә хезмәт күрсәтә торган транспорт чараларын агымдагы карап тотуга норматив еллык чыгымнарны исәпләү тәртибендә:

2.1 нче пунктта «Машина йөртүченең хезмәте өчен түләү «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларына каршы килә алмый.» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.4 нче пунктта «Яңадан файдалануга тапшырыла торган ашыгыч медицина ярдәме автомобильләре өчен 1 елга 27 360 сумга тигез булган күләм кулланыла. сүзләрен төшереп калдырырга;

2.8 нче пунктның җиденче абзацы үз көчен югалткан дип санарга;

карарга дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренең оператив идарәсендә булган ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен транспорт чараларын агымдагы карап тотуга норматив еллык чыгымнарны (карарга теркәлә) өстәргә;

карарга ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен транспорт чараларына аутсорсинг хезмәтләре күрсәтүгә түләү өчен норматив чыгымнарны (карарга теркәлә) өстәргә;

карарга Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен транспорт чараларын агымдагы карап тотуга норматив еллык чыгымнарны исәпләү тәртибен (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин